ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«09» март 2023 ел № 27-р

«Гаилә тарихында гасыр кайтавазы - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең зона этабына әзерлек турында

Татарстан Республикасы дәүләт комитетының 17.01.2023 елның 3–од номерлы боерыгы белән расланган «Гаилә тарихында гасыр кайтавазы - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален уздыру турындагы нигезләмәне үтәү, милли традицияләр бергәлеге нигезендә гаилә һәм гаилә-туганлык элемтәләрен ныгыту, үз төрен, халкын, туган якны өйрәнү, гаилә иҗатына ярдәм итү һәм аны үстерү, аның эстетик, яшь буынга әхлакый һәм рухи тәрбия бирү максатында:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы» МБКУ директоры О. В. Михайлованы Татарстан Республикасы Зәй шәһәрендә уздырыла торган «Гаилә тарихында гасыр кайтавазы - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең зона этабына Матвеевлар гаиләсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат итеп билгеләп куярга

2. «Гаилә тарихында гасыр кайтавазы - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең зона этабына әзерлек вакытында, Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 17.01.2023 елның 3-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Зәй шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Гаилә тарихында гасыр кайтавазы - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален уздыру турындагы нигезләмәгә таянып эш итәргә.

3. Әлеге күрсәтмәне "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Э. Н. Бонькинга йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**